СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

## КАРАРЫ

**2015 елның «22» сентябреннән** **№ 1-4**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының вәкаләтләр срогы чыкканга күрә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә (алга таба – Конкурс).
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итү 2015 елның 25 сентябреннән 2015 елның 14 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча башкарыла: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80, каб. 209, 8.00-17.00 сәгатьләрдә, һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән кала.

2. Конкурс комиссиясен 15 октябрьдә 14 сәгатьтә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы бинасында түбәндәге адрес буенча : Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет ур., 80, 426 каб. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2005 елның 27 октябрендәге 6 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында» Нигезләмә нигезендә үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүматны Яңа Чишмә муниципаль районы Советына бирергә.

3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясенең составын 6 кешедән расларга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составының яртысын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында 2015 елның 25 сентябрендә бастырып чыгарырга һәм «Интернет»челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның «22» сентябрендәге
1-4 номерлы карына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

1. Попкова Надежда Ивановна - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары.
2. Җәләлетдинов Җәүдәт Мәхмүт улы - Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге башлыгы.
3. Губкина Мария Дмитриевна - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче.